**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«02» август 2019 ел Кече Шилнә авылы № 39

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннарны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 маддәсе 8 өлеше һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» 2019 елның 10 июлендәге 67/516 санлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

– Кече Шилнә авылы, Центральная ур., 4А й., мәгълүмат стенды, ФАП;
– Кече Шилнә авылы, Центральная ур., 4 й., мәгълүмат стенды;;
– Олы Шилнә авылы, Титова ур., 36 й., мәгълүмат стенды;
– Ильбухтино авылы, Верхняя ур.,6 й., 1, мәгълүмат стенды;
– Ильбухтино авылы, Центральная ур., 23А й, мәгълүмат стенды, ФАП;
– Белоус,Центральная ур., мәгълүмат стенды; ФАП.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Г.Даутов

Совет МАЛОШИЛЬНИНСКОГО сельского поселения